ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2024 Балык Бистәсе штп. № 293пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 18.12.2023 №417пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясындагы $3^2$ пунктының өченче абзацы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 18.12.2023 №417пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә «Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» бүлеген түбәндәге эчтәлектәге юл белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| 811 | 2 02 45050 05 0000 150 | Дәүләт гомуми белем бирү оешмаларының, Россия Федерациясе субъектларының, Байконур шәһәренең һәм "Сириус" федераль территориясенең һөнәри белем бирү оешмаларының, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының һәм һөнәри белем бирү оешмаларының балалар иҗтимагый берләшмәләре белән тәрбия һәм үзара хезмәттәшлек буенча директорлар киңәшчеләренә айлык акчалата бүләкләү түләүләрен тәэмин итүгә муниципаль районнар бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә, 2024 елга бюджеттан башлап барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов